ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧЕТЫРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422969, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Четырчи, ул. Зеленая, 14

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЫТЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422969, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Чытырчы авылы,
Зеленая ур., 14

тел./факс 8(84342) 3-21-47 e-mail: Ctr.Ctp@tatar.ru

Постановление                                        Карар

2020 елның 16 июле                                        №8

Сайлау алды басма агитация материалларын
урнаштыру өчен махсус урыннар турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Чистай муниципаль районы Чытырчы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, белдерүләр стендларында һәм такталарында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чытырчы
авыл җирлеге башлыгы ______________ М.В.Новиков

Чытырчы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 16 июлендәге
8 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Президенты, дүртенче чакырылыш Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге Советы депутатлары сайлауларын һәм 2020 елның 13 сентябрендәге 28 номерлы Түбән Кама бермандатлы сайлау округы буенча җиденче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты өстәмә сайлауларын үткәргәндә Чистай муниципаль районының Чытырчы авыл җирлеге территориясендә сайлау алды басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын адресы | Урнаштыру урыны исеме |
|---|---|---|
| 2763 | 422969, ТР, Чистай районы, Чытырчы авылы, Зеленая ур. | Чистай РАЙПО кибете янындагы мәйданчык мәгълүмат стенды |